| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | | ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» февраля 2022г. с. Тюлячи № 15

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең генераль планы проектын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару турында кагыйдәләрен эшләү турында

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге башкарма комитетының 2022 елның 10 февралендәге 7 номерлы хатын карап, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең генераль планы проектын, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару турында кагыйдәләрен эшләүгә керешергә.
2. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге тарафыннан төзелгән техник бирем нигезендә проектны эшләүне гамәлгә ашырырга.
3. Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлегенең генераль планы проекты, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару турында кагыйдәләре проектына заказчы итеп Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 25, 31 статьялары таләпләре нигезендә проектны карау, килештерү, раслауны үткәрергә.
5. Әлеге карарны гамәлдәге законнар нигезендә бастырып чыгарырга.
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлеевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин